**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы карары**

**2024 елның 11 ноябре** **№6**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 20 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ямбулат-Пустошь авылы, Яшел урамы, 16 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала,Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ямбулат-Пустошь авылы урамнарындагы яктырту челтәрләрен, трансформаторны һәм алар өчен бүтән төрле подстанцияләрне, участокларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җибәрү өчен эшләнәсе эшләр (җиһазларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, контракт буенча эш өчен түләү, смета эшләү һәм түләү), урам яктырту хезмәтен башкару, урам яктырту, компонентларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, контракт буенча эш өчен түләү, урам

яктыртуын тәэмин итү буенча сметаларны эшләү һәм түләү, башка төр эшләр;

- Ямбулат-Пустошь авылын янгын куркынычсызлыгы буенча төп чаралар белән тәэмин итү (янгын сүндерү җиһазларын һәм компонентларын сатып алу, ташу, урнаштыру һәм хезмәт күрсәтү, смета документларын эшләү һәм түләү, контракт буенча эш өчен түләү, техник күзәтчелек, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен башка эш төрләре белән тәэмин итү;
- Ямбулат-Пустошь авылында халык яшәгән территорияне яхшырту (билге (вывеска) алу һәм урнаштыру; җәйдә территорияне яшелләндерү, халык яшәгән территорияне төзекләндерү, материаллар алу һәм ташу, эш һәм контракт буенча хезмәтләр өчен түләү, проект сметаларын эшләү һәм түләү, техник күзәтчелек, һәм башка төр торак пункт территориясен төзекләндерү өстендәге эшләр;
- Ямбулат-Пустошь авылында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау (урам юлларына таш җәю,таш белән ямау,таш һәм материаллар сатып алу,ташны ташу һәм салу, контракт буенча эш өчен түләү, проект сметаларын эшләү һәм түләү, техник күзәтчелек үткәрү, кышын кардан чистарту, гидротехник материаллар, запчастьләр сатып алу, контракт буенча эш һәм хезмәт өчен түләү, сметалар эшләү һәм түләү, күпер төзү һәм ремонтлау, урнаштыру; юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр;
- Ямбулат-Пустошь авылында җир асты суларының табигый чыганакларын (чишмәләрне) яхшырту (территориясен яхшырту, коймаларны һәм баскычларны ремонтлау һәм буяу, материаллар алу һәм ташу, контракт буенча эш һәм хезмәт өчен түләү, проект сметаларын эшләү һәм түләү, техник күзәтчелек, җир асты суларының табигый чыганакларын яхшырту буенча башка төр эшләр;
- Ямбулат-Пустошь авылында (мәдәни мирас объектлары булмаган (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) Россия Федерациясе халыкларының һәйкәлләре) һәйкәлләр төзү, ремонтлау, территориясен төзекләндерү (һәйкәлне саклау, смета документларын эшләү һәм түләү, эш өчен түләү, техник күзәтчелек, һәйкәлләрне төзекләндерү һәм ремонтлау буенча башка төр эшләр);
- Ятмас Дусай авылында җәяүлеләр күперләрен һәм күперләрне төзү, җәяүлеләр күперләрен ремонтлау (җәяүлеләр күперен урнаштыру, ремонтлау, смета документларын эшләү һәм түләү, контракт буенча эш өчен түләү, техник күзәтчелек, җәяүлеләр күперләрен һәм күперләрне ремонтлау буенча башка төр эшләр).

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: А.И. Шаймарданова

ОГРН 1021607753155
ИНН 1623001685